БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2025ел № 313

**2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү муниципаль оешмалары укучыларын тукландыруны тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 елларның план чорына дәүләт гомуми белем бирү оешмаларындагы төп гомуми һәм урта гомуми белем программалары буенча белем алучылар, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итү бәясенең күләмен раслау турында» 2025 елның 3 октябрендәге 786 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга һәм 2027–2028 елларның план чорына Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем программалары буенча белем алучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүне оештыруга тотылачак норматив чыгымнарны, һәм башлангыч гомуми белем программалары буенча бер укучыга кайнар тукланунының уртача бәясен раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 9 январеннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен һәр уку көненә 77 сум 76 тиенлек бушлай туклану оештырырга.

2. 2026 елның 9 январеннан Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруга Балтач муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 10 сум 70 тиен күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 январеннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов